КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 гыйнвар г.Казань № 25

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 март, 171 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 март, 171 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 август, 602 нче; 2024 ел, 25 ноябрь, 1051 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Ярминкәләр транспорт һәм җәяүлеләр өчен йөрү мөмкинлеге тәэмин ителгән, автомашиналардан (автолавкалардан, автокибетләрдән) сатуны оештыру мөмкинлеге булган, каты өслекле, төзекләндерелгән территориядә, вакытлыча урнаштырылган палаткаларда һәм башка сәүдә урыннарында үткәрелә.

түбәндәге эчтәлекле 2.10 пункт өстәргә:

«2.10. Ярминкәне оештыручыга товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен урыннар бүлеп биргәндә дискриминация шартларын тудыру тыела.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин